**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ XX СЕССИЯСЕ**

**К А Р А Р № 110**

Мөслим авылы «30» август 2022 ел

**«Мөслим муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы турындагы Нигезләмәне раслау хакында» Мөслим муниципаль районы Советының 2014 елның 05 ноябрендәге 215 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 24 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән, Мөслим районы прокуратурасының 2022 елның 30 июнендәге 02-01-12-2022 номерлы хатын карау нәтиҗәләре буенча, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль район Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. «Мөслим муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы турындагы Нигезләмәне раслау хакында» Мөслим муниципаль районы Советының 2014 елның 05 ноябрендәге 215 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- «Палатаның эшен оештыру» 6 бүлегендәге 6.1 п. финанс-бюджет палатасы турындагы нигезләмәләрне яңа редакциядә бәян итәргә:

«6.1 Палатаны район җирле үзидарәсенең вазыйфаи заты булган рәис җитәкли, Палата эшчәнлеге белән җитәкчелек итә һәм аның эшен оештыра.

Палата рәисе вазыйфага Мөслим муниципаль районы Башлыгы тәкъдиме белән Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе итеп билгеләнә һәм муниципаль район финанс органы җитәкчесе вазыйфасына кандидатларның Татарстан Республикасы финанс органы катнашында квалификация таләпләренә туры килү-килмәвен тикшерү үткәрү тәкъдиме белән Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе итеп билгеләнә.

Палата рәисе үз вазыйфасына Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән квалификация таләпләренә җавап бирүче затлар арасыннан билгеләнә.

Палата рәисе Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары булып тора.».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мөслим муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Р.Г. Гариповка йөкләргә.

Мөслим муниципаль районы Башлыгы,
Мөслим муниципаль районы Советы рәисе А.Р. Хуҗин